ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БОЛЬШЕЕЛОВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН
ОЛЫ ЕЛОВО АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

“17” август 2024ел. Олы Елово авылы № 11

Кararга үзгәрешләр кертү турында

Алабуга муниципаль районы Олы Елово авыл җирлеге башкарма комитетының 21.11.2023 елның 8 № - лы " Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Олы Елово авыл җирлеге бюджеты керемнәренең җирле үзидарә органнары булган һәм (яисә) алар карамагындагы казна учреждениеләре тарафыннан бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында»

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 13.07.2024 ел, № 177-ФЗ Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Олы Елово авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Олы Елово авыл җирлеге Башкарма комитетының 21.11.2023 №9 карары белән расланган Җирле үзидарә органнары булган һәм (яисә) алар карамагындагы казна учреждениеләре бюджет керемнәренең Баш администраторлары тарафыннан бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4 пунктның җиденче абзацында «бирәләр» сүзеннән соң «түләнергә тиешле сумманы исәпләү көненнән дә соңга калмыйча»сүзләрен өстәргә.;

1.2. 4 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

»- Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләргә туры китереп эшләнгән бюджетка түләүләр, пенялар һәм алар буенча штрафлар буенча дебитор бурычларын түләтү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру регламентын билгелиләр".

1.3. 5 пунктның б пунктчасының алтынчы абзацында «тапшыру» сүзеннән соң «түләнергә тиешле сумманы исәпләү гамәлгә ашырылган көннән дә соңга калмыйча»сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан мизгелдән үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Җитәкче А.И.Машанов